Минем әни, Миниямал Шәйхеләхмәт кызы, 1923 елның 30 сентябрендә Бәзәкә авылында баш бала булып дөньяга килә. Бала һәм үсмер чаклары ачлык һәм сугыш елларына туры килә аның. Күпме авырлыклар кичерергә туры килә аңа! 9 яшеннән ат җигеп колхоз эшләрендә катнаша.

Әтисе Шәйхеләхмәт 1936 елда донос белән гаепсезгә төрмәгә эләгә һәм шунда үлә. 1,5 елдан әнисе Хөсниҗамал бер уч ашлык өчен төрмәгә озатыла. Өйдә әнигә 2 сеңлесе: Әминә белән Мәдинә; 2 энесе: Нуриәхмәт белән Хаҗиәхмәт кала. Күп тә үтми, кече энеләре Хаҗиәхмәт, ачлыктан шешенеп, вафат була. Бу вакытта әнигә бары тик 14 яшь була.

Әни 13 яшендә гади атчы булып колхозга эшкә урнашкан була. Ә хезмәт кенәгәсе аңа 1939 елда 16 яшь тулгач кына ачыла.

Авыр сугыш елларында әнигә бригадир хезмәтен дә, өлкән конюх вазифасын да башкарырга туры килә. Сугыш елларында тылдагы хезмәтләре өчен 1953 елда әнигә һәм авылдагы 2 ир-атка беренчеләрдән булып “За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941-45г.г.” медале тапшырыла.

Сугыштан соң ,1947 елда, әни 1940 елда армия сафларына алынып, 1945 елда сугыш кырыннан җиңү яулап, авылга исән-сау әйләнеп кайткан Сәлимуллин Хәмәт Хикмәт улы белән гаилә кора. Әкренләп үзләренең көче белән тормыш башлап җибәрәләр. 5 ел буе түземсезлек белән бала көтәләр. Инде уллыкка бала алырга уйлашкач, әни үзенең авырлы икәнен сизеп ала. Ул дөньяга бер-бер артлы 8 бала китерә. Кызганычка каршы, өч баласы яшьли бакыйлыкка күчә. Калган бишебез әти-әни канаты астында, гадел, хезмәт сөючән гаиләдә тәрбия алдык.

Әни 1969 елда сельпога возчик булып урнаша. Әни безнең көнелләрдә үзенең көчле рухы, ныклы характерлы булуы белән истә калды. Әнә шул сыйфатлары аны һәрвакыт яңалыкка этәрә..

1971 елның сентябрендә хуҗалык рәисе Ахмеров Баян Вәлиевич тарафыннан хатын-кызлар өчен трактористлар курсы оештырылуын белгәч, ул беренчеләрдән булып гариза яза. Яшен 46 яшь итеп күрсәтә. Әнигә бу вакытта 48 яшь һәм арада иң өлкәне ул була. Бу курска 80 нән артык хатын-кыз гариза яза.

4 класс белеме генә булуына карамастан, әни бик тырышып укый. Без кичләрен бергә уку материалларын гомуми дәфтәргә күчерергә, экзамен билетларына җаваплар язарга булыша идек. Курста теория белән практиканы авылдашыбыз Шәймөхәмәтов Әхәт Касыйм улы алып барды.

Ниһаять, 1972 елның язында, имтиханнарны уңышлы тапшырып, алты хатын-кыз: Сәлимуллина Миниямал, Сәлимуллина Фатыйма, Шәрәфетдинова Наталья, Шәяхмәтова Нәҗибә, Шәймәрданова Гәздәбикә, Хәбибуллина Саҗидә Липецк трактор заводында чыгарылган өр-яңа Т-40

тракторлары руле артына утырып эш башлыйлар. Бу бригаданы “Беренче карлыгачлар” дип атадылар.

Әни үз һөнәрен яратып, вакыт белән исәпләшмичә, бер эштән дә курыкмыйча, намус белән эшли. Чөнки кечкенәдән үк барлык эшләрне хөрмәт итәргә өйрәнгән. Нормасын 150-170 процентка үтәп барды. Урып-җыю вакытларында, терлек азыгы әзерләгәндә, җәйге мал лагерьларына силос илтүдә иртәдән кичке караңгыга кадәр, һава торышының нинди булуына карамастан, хезмәт куйды. Кыш-яз басу-кырларга тирес, черемә ташый. Моннан тыш, кышын 4 терлекчелек фермасының тиресен чыгара, маллар астына Менделеевск пилорамасыннан пычкы чүбе алып кайтып тарата, силос белән тәэмин итеп тора. Вакыт белән исәпләшмичә һәр эшне җиренә җиткереп башкаруы, никадәр җаваплы кеше булуы турында әнинең 75 еллык юбилеенда колхоз хуҗалыгы рәисе Галимов Ибраһим Миндар улы сокланып, ассызыклап сөйләде.

Әнинең тракторы белән капиталь ремонтка туктаганын хәтерләмим. Монда әтинең дә өлеше зур булгандыр дип уйлыйм. Әти гомере буе машина руле артында булды. Техниканы бик яхшы белә иде. Болардан тыш, әни дә, әти дә күршеләргә, авылдашларга техникалары белән хуҗалык эшләрендә дә булыша иделәр.

Әти авырып китү сәбәпле, әни эшеннән 66 яшендә туктады. Ләкин 70 яшендә дә, күршенең тракторына утырып элдертеп чапканы хәзер дә күз алдымда тора...

Әниемнең хезмәте хөкүмәтебез тарафыннан югары бәяләнә. 1972 елның 15 декабрендә “За трудовое отличие” медаленә лаек була. 1974 елда Алабуга районы механизаторлары арасында “Лучший механизатор” исемен ала. 1975 елда тракторчы хатын-кызлар белән Мәскәүдә Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә (ВДНХ) катнаша. Әнинең фотосы районның Почет тактасына куела. Шулай ук әни “Хезмәт ветераны” медале белән бүләкләнә, аңа “Атказанган колхозчы” исеме бирелә. Ул күпсанлы мактау кәгазьләренә, кыйммәтле бүләкләргә лаек була.

Әтием Сәлимуллин Хәмәт Хикмәт улы 1990 елның 20 мартында, әнием Сәлимуллина Миниямал Шәйхеләхмәт кызы 2003 елның 29 сентябрендә вафат булдылар.

Без, балалары - Мансур, Мининур, Мансура, Гөлфирә, Илсөяр әти-әниебезгә чиксез рәхмәтле! Бүгенге көндә әти-әнинең киңәшләрен тотып, бер-беребезне хөрмәт итеп, аралашып-ярдәмләшеп яшибез.

*Гайфетдинова Мининур Хәмәт кызы. 2022 ел, март*

















САЛИУЛЛИНА МИНИЯМАЛ ШАИХЛАХМЕТОВНА

- Трактористка













Бизякинский с/совет
(учреждение, выдавшее удостоверение)



Серия Д № 320111

...милия Салимуллина
... Минниямал
...ство Шайхулахметовна
...ная подпись

Предъявитель удостоверения имеет право на льготы и преимущества, установленные законодательством для лиц, награжденных орденами и медалями СССР за самоотверженный труд и безупречную воинскую службу в тылу в годы Великой Отечественной войны.

УДОСТОВЕРЕНИЕ БЕССРОЧНОЕ
И ДЕЙСТВИТЕЛЬНО НА ВСЕЙ ТЕРРИТОРИИ
СОЮЗА ССР

Дата выдачи „29" апреля 1993 г.

(подпись руководителя учреждения)

М. П.

Л. т. 12.



Салимуллина
(фамилия)

Минниямал
(имя)

Шайхулахметовна
(отчество)

Награжден медалью

„За трудовое отличие"

Указом Президиума Верховного Совета СССР

от „15" декабря 1972 г.

Секретарь Президиума
Верховного Совета СССР Георгадзе

З № 178646

„4" января 1973 г.

жить личным примером сознательности в выполнении своего гражданского долга, быть образцом добросовестности и аккуратности при исполнении государственных обязанностей.

из Положения о медали „За трудовое отличие"

(Утверждено Указом Президиума Верховного Совета СССР от 27 декабря 1938 г.).

1. Медалью **„За трудовое отличие"** награждаются рабочие, колхозники, служащие, инженерно-технические и хозяйственные работники, работники транспорта, строительств, торговых и кооперативных организаций, культурных и научных учреждений за выдающуюся ударную работу, высокие производственные показатели и заслуги в развитии науки, техники и культуры.

2. Медалью **„За трудовое отличие"** награждает Президиум Верховного Совета СССР.

7. Награжденный медалью **„За трудовое отличие"** должен носить ее с честью, слу-

9

## СВЕДЕНИЯ О РАБОТЕ

| Дата записи (год, месяц и число) | За какой год даются сведения | В качестве кого работал | Начислено трудодней за год | Количество отработанных человеко-дней за год | Установленный минимум трудодней (или человеко-дней) за год | Начислено за год денег (рублей) | кроме того, натурой (кг) | | | | | Подписи лиц, удостоверяющих записи, и печать колхоза: председатель колхоза | главный (старший) бухгалтер колхоза |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| 25/V-68 | 1954 | рядовая | 19 | | | | | | | | | | |
| " | 1955 | —"— | — | | | | | | | | | | |
| " | 1956 | —"— | 18 | | | | | | | | | | |
| " | 1957 | —"— | 7 | | | | | | | | | | |
| " | 1958 | —"— | 58 | | | | | | | | | | |
| " | 1959 | —"— | 32 | | | | | | | | | | |
| " | 1965 | —"— | 10 | 11 | | | | | | | | | |
| " | 1966 | —"— | 41 | 11 | | | | | | | | | |
| " | 1967 | —"— | — | 16 | | | | | | | | | |
| " | 1968 | —"— | — | 13 | | | | | | | | | |

Работа в качестве члена колхоза с
1939 года по 1953 год Протокол № 619
Совета социального обеспечения

# Трудовая книжка

Фамилия Саммуллина

Имя Миннимал

Отчество Шайхлахмедовна

Год рождения 1923

Образование: начальное, среднее, высшее (подчеркнуть)

Профессия Возчик

Подпись владельца Трудовой книжки

Дата заполнения Трудовой книжки 23. марта 1969 г.

Елабужский райсо Татарской АССР
Пенсия назначена 21/III 1974 г.

От имени Президиума Верховного Совета СССР Указом Президиума Верховного Совета ТАССР

30 мая 1964.

награждена медалью

„Медаль материнства"

II степени

Президиума Верховного Совета

..... 19.... года

Е № 858968

## ПОЛОЖЕНИЕ

### о медали „Медаль материнства"

(Утверждено Указом Президиума Верховного Совета СССР от 18 августа 1944 г.).

1. Медалью „Медаль материнства" награждаются матери, родившие и воспитавшие пять и шесть детей.

2. Награждение медалью „Медаль материнства" производится от имени Президиума Верховного Совета СССР Указами Президиумов Верховных Советов союзных и автономных республик.

3. Медаль „Медаль материнства" состоит из двух степеней:

„Медаль материнства" I степени;

„Медаль материнства" II степени.

Высшей степенью медали является I степень.

4. Медалью „Медаль материнства" награждаются:

матери, родившие и воспитавшие пять детей,— медалью II степени;

матери, родившие и воспитавшие шесть детей,— медалью I степени.